Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
3 нче номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

# Зурлар, әзерлек төркеме балалары өчен җырлар һәм «Body Percussion» схемалар җыентыгы

**Автор һәм төзүче:
музыка җитәкчесе
Винокурова С.А.**

Чистай шәһәре, 2026ел.



Зурлар, әзерлек төркеме балалары өчен җырлар һәм «Body Percussion» схемалар җыентыгы/төз.: Винокурова С.А.: Татарстан Республикасы Чистай районының «Кояшкай» 3 нче балалар бакчасы», 2026 ел.

Әлеге җыентык 5-7 яшьлек балаларда ритм хисен үстерү өчен каралган.

Балалар җырлары һәм картотека схемалары тәрбияләнүчеләрдә ритм хисе уята, музыкаль эшчәнлек белән кызыксыну теләген уята.

Җыентык мәктәпкәчә мәгариф оешмаларда эшләүче белгечләрнең киң даирәсенә билгеләнгән һәм балаларның ялын оештырганда ата-аналар тарафыннан файдаланылырга мөмкин.

# Эчтәлек

**Мәгълүматнамә**

***1 бүлек «Төсле»***

«Яз җитә»

«8 март»

«Ак куян»

«Бииләр итек, читекләр»

***2 бүлек «Катнаш»***

«Бар монда»

«Татар халык җыры»

«Дәү әнигә бүләккә»

«Әбием-әбекәем»

«Туган тел»

**Мәгълүматнамә**

*Җыентыкның максаты* – музыкаль ритм төшенчәсе белән таныштыру.

Сезнең игътибарыгызга «Body Percussion» схемалары белән балалар җырларын тәкъдим итәбез.
Җыентыкта 2 бүлек бар:
1 бүлек «Төсле»;
2 бүлек «Катнаш.»

Беренче бүлектә "Body Percussion" схемалары төсләр буенча аерыла.
Катнаш бүлектә схемалар график рәсемнәр ярдәмендә күрсәтелә.

Тәкъдим ителгән материал балалар бакчалары тәрбиячеләренә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның әти-әниләренә файдалы булачак



# Төсле схемалар

| Күнегү исеме: | Төсе |
| --- | --- |
| 1.«Тычкан» |  |
| 2.«Сандугач,күгәрчен» |  |
| 3. Аяк чабу |  |
| 4.Бот чабу |  |
| 5. «Кул чабу» |  |

6. «Аяк дөбердәтү»

7. «Песикәй»

8. «Күбәләк»

9. «Яңаклар»

10. «Кар бөртеге»

11. Чиртеш



**«Яз житә»**

1.Кояш көлеп карый безгә,
Күзләр чагыла,
Елгалардан бозлар ага
Диңгез ягына.

Яз, яз, яз җитә,
Тәрәзәне ачтылар,
Тып, тып, тып итә
Эре-эре тамчылар.

2.Агачка кунып чыпчыклар
Чыелдашалар,
Яшькелт-кара сыерчыклар
Әй җырлашалар.



# «8 март»

1.Кояш көлә, мин елмаям,
8 нче Март бүген.
Буген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.

Пр-в:
Бәйрәм бүген, бәйрәм, диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнне
Әти дә белеп торсын,
Әти дә келеп торсын.

2.Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын
Әниләрнең күңеледәй
Бөтен нәрсә пакъ булсын.




## «Ак куян»

1. Ак куян, йомшак куян,
Безгә кунакка килгән.
Койрыгы кыска гына,
Колагы жиргэ тигән.



2. Әйдә без кунакларны
Кишер белэн сыйлыйбыз.
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Сикерешеп уйныйбыз.





## «Бииләр итек, читекләр»

1.Гармун уйныйм, гармун уйныйм.

Һаман гармун уйныйм мин.

Остарып җиткәч барсында

Биетергә уйлыйм мин.

Остарып җиткәч барсында

Биетергә уйлыйм мин.

2. Учларыңны шапылдатып

Чәчләреңне сыпыр да.


Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,

Тыпыр-тыпыр, тыпыр дап.

## Катнаш схемалар

| **Күнегү исемнәре:** | **Рәсемнәре** |
| --- | --- |
| 1. «Мышка» |  |
| 2. «Сандугач, күгәрчен» |  |
| 3. Аяк чабу |  |
| 4. Бот чабу |  |
| 5. Кул чабу |  |

6. Аяк дөбердәтү



7. «Песикәй»



8. «Күбәләк»



9. Яңаклар



10. «Кар бөртеге»



11. Чиртеш





# «Бар монда»


Бар монда зур төлке,

Зур төлке, матур төлке – 2 тапкыр

припев:

Төлке, төлке, кил әле,

биеп, биеп кит әле – 2 тапкыр






2.Бар монда зур аю,

зур аю, матур аю – 2 тапкыр

припев:

Аю, аю, кил әле,

биеп, биеп кит әле – 2 тапкыр






# Татар халык җыры

Бу - бик яхшы укучы,

Бу - бик яхшы укучы.

Аның укуы яхшы - аннан үрнәк алыгыз,

Аның укуы яхшы - аннан үрнәк алыгыз.






Кәрия-Зәкәрия коммая,

Кәрия-Зәкәрия коммая.

Кәри комма, Зәкәрия, Зәкәрия коммая.

Кәри комма, Зәкәрия, Зәкәрия коммая.



# «Дәу әнигә буләккә»

1 Җиләк җыям чиләккә

Дәу әнигә буләккә


Ул буләккә шатланыр

Мине тагын яратыр

Кушымта:

Буләккә, буләккә

Җиләк җыям чиләккә






# «Әбием – әбекәем»

1.Балам, дия – дия безне

Кадерләп үстерәсең,

Әй, матур син, әбекәем,

Күзләр тия күрмәсен!



## «Туган тел»

3.И туган тел! hәрвакытта

Ярдәмең берлән синең

Кечкенәдән аңлашылган

Шатлыгым, кайгым минем

